ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

КАРАР

07.12.2017 ел Яр Чаллы № 5679

«Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Әҗмәкәй авыл җирлеге, Әҗмәкәй т. п., Ш. Камал урамы адресы буенча урнашкан индивидуаль торак йортларны газ белән тәэмин итү» проекты буенча халык тыңлауларын билгеләү турында

РФ Шәһәр төзелеше кодексының 28, 45 һәм 46 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законы, Татарстан Республикасы «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, «халык тыңлауларын үткәрү тәртибе турында» нигезләмә нигезендә, кешенең уңайлы тормыш шартларына хокукларын, җир кишәрлекләренә һәм капиталь төзелеш объектларына хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатыннан,

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Әҗмәкәй авыл җирлеге, Әҗмәкәй т. п., Ш. Камал урамы адресы буенча урнашкан индивидуаль торак йортларны газ белән тәэмин итү» объекты буенча территорияне планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча халык тыңлауларын билгеләргә.
2. Билгеләргә:

2.1. халык тыңлауларын үткәрү вакытын -1 9.01.2018 15.00 сәг.;

2.2. үткәрү срогы - әлеге карар басылып чыккан көннән алып халык тыңлаулары нәтиҗәләре турында бәяләмә бастырылган көнгә кадәр кимендә бер һәм өч айдан да артык түгел;

2.3. үткәрү урыны - Яңа поселогы, Үзәк урамы, 1 йорт, Кече зал адресы буенча мәдният йорты;

2.4. тикшерелә торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр белдерү, халык тыңлауларында катнашырга заявкалар бирү өчен адрес: Яңа поселогы, Үзәк ур., 1, каб.№ 3, № 5 (эш көннәрендә-8.00 дән 16.20 гә кадәр);

2.5. чыгыш ясау хокукы белән халык тыңлауларында катнашуга заявкалар бирү срогы - с 08.12.2017г. - 16.01.2018г.

3. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә әлеге карарны рәсми матбугат басмасында («Якты юл» («Светлый путь») газетасы) бастырып чыгарырга, Тукай муниципаль районының рәсми сайтында tukay.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгхълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге башлыгы урынбасары - баш архитектор М.Т. Шәмсиевга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Р.Т. Гыйзатуллина

.i-